ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06 10 2023 г. № 949

«2017 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру турында» Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 июлендәге 476 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 июлендәге 476 номерлы карары белән расланган Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында социаль якланмаган гаиләләрдән укучыларны тукландыруны оештыру тәртибе турында Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«2.1. Инвалид балаларга караган укучылар категориясе ике тапкыр бушлай туклану белән тәэмин ителә»;

карарга кушымтаның икенче таблицасын кушымта итеп бирелгән яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 01 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы А.Х. Гарифуллинга йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның «06» октябре
949 номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында

түбәндәге категория балалар өчен туклану бәясе

| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Ике тапкыр туклану 1-4 сыйныф | | | | |
| Гомуми белем бирү оешмалары | Туклану бәясе, сум | Муниципаль бюджет | Республика бюджеты | Федераль бюджет |
| шәһәр | 115,14 | 50,95 | 28,83 | 35,36 |
| авыл һәм Кама Аланы штп | 115,14 | 50,95 | 28,83 | 35,36 |
| Ике тапкыр туклану. Бер тапкыр туклану 5-11 сыйныф | | | | |
| Гомуми белем бирү оешмалары | Туклану бәясе, сум | Муниципаль бюджет | Республика бюджеты | Федераль бюджет |
| шәһәр | 119,50 | 110,70 | 8,80 | - |
| авыл һәм Кама Аланы штп | 101,40 | 92,60 | 8,80 | - |